# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Свияжский (Зөя)авыл
җирлеге торак пунктында

2023 елның 17 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Свияжский (Зөя) авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Свияжский (Зөя) авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, мобилизацион гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
- Свияжский (Зөя) авыл җирлеге территориясендә балалар спорт мәйданчыгын төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Свияжск (Зөя) авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск муниципаль районы, Свияжск (Зөя) авылы, Успенская урамы, 11 йорт (поселение администрациясе), Успенская урамы, 2 йорт (кибеткә керү урынында).

Гражданнар җыенында
рәислек итүче Ганеев М.Г.